**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ИБРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

№ 35 19.01.2017ел

**Татарстан Республикасы**

**Аксубай муниципаль районы**

**»Яңа Ибрай авыл җирлеге"**

**муниципаль берәмлек Уставына**

**үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 13 - ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Уставының 81, 82, 83 статьялары нигезендә Яңа Ибрай авыл җирлеге Советы карары:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яңа Ибрай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Юстиция органына Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр дәүләт теркәвеннән соң махсус мәгълүмати стендларда игълан ителергә тиеш.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе Ф.Х.Кәбиров

кушымта№ 1
"Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге
Советы карарына
19.01.2017ел № 35

**"Татарстан Республикасы**

**Аксубай муниципаль районы**

**»Яңа Ибрай авыл җирлеге"**

**муниципаль берәмлек Уставына**

**үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында".**

1.7 статья 15 пункт белән тулыландырылсын:

«(15) Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру.».

2. 47 статьяның 2 өлеше түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырылырга:

Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чаралар үткәрә